Татарстан Республикасы Президенты каршындагы
Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе
утырышына чыгыш проекты

***«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү системасында өстенлекле эш юнәлеше буларак милли мәгариф»***

***Хәерле көн, хөрмәтле Марат Готович,***
***хөрмәтле комиссия әгъзалары!***




Туган телне саклау һәм үстерү, аны өйрәнү өчен шартлар тудыру мәгариф системасының өстенлекле эш юнәлеше. Һәм аның әһәмияте елдан-ел арта.




2021 елның туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителүе, Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү Комиссиясе, милләтара һәм конфессияара мәсьәләләр Советы эшчәнлеге әлеге өлкәгә аеруча зур игътибар бирелүен раслый.

Бу юнәлештә күпсанлы программалар һәм проектлар тормышка ашырыла.




Республикабыз уку йортларында белем һәм тәрбия бирү «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законы,*«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы законы*, федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә тормышка ашырыла.

Югарыда саналган **кануннар нигезендә**, Россия гражданнары **туган телдә мәктәпкәчә, башлангыч** һәм **төп** гомуми **белем алуга**, шулай ук **туган телне өйрәнүгә хокуклы**. Ә **урта белем алуны рус телендә** оештыру билгеләнә.




Россия Мәгариф министрлыгы боерыклары белән башлангыч һәм төп гомуми белем бирүнең яңартылган стандартлары расланды.Анда Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телен сайлап алу мөмкинлегебар һәм

улуку планының мәҗбүри өлешендә булган «Туган тел һәм әдәбият» предметы өлкәсенә кертелгән.




Канун нигезендә белем бирү телен һәм туган тел буларак өйрәнү телен сайлау укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Яңартылган стандартлар 2022 елның 1 сентябреннән кертеләчәк.

Стандартларда рус телендә белем бирүче мәктәпләр өчен, Россия халыклары телләре һәм республикаларныңдәүләт теле уку йортының мөмкинлекләреннән чыгып һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы буенча гамәлгә ашырыла – дигән искәрмә куелган. Бу исә ата-аналар тарафыннан уку предметы сыйфатында туган тел сайланмаганда, «Туган тел һәм әдәбият» предмет өлкәсенең мәҗбүрилеген инкарь итә һәм фикер каршылыклары китереп чыгарырга мөмкин.




Хәзерге вакытта Россия мәгариф академиясенең мәгарифне үстерү стратегиясе институты тарафыннан төп белем бирү программаларының якынча проектлары эшләнгәнде һәм «Гомуми белем бирүнең бердәм эчтәлеге» сайтына урнаштырылды.

Югарыда әйтелгән искәрмә нигезендә әлеге документларда булган уку планнарының кайбер вариантларда «Туган тел һәм әдәбият»фән өлкәсен өйрәнү төшереп калдырылган.

Безнең тарафтан Татарстан Республикасы Президенты имзасы белән Россия Федерациясе мәгариф министры исеменә проектларга “Туган тел һәм әдәбият” предмет өлкәсен укытуны оештыру буенча төзәтмәләр кертү кирәклеге турында хат юлланды, Мәгарифне үстерү стратегиясе институтына һәм федераль укыту-методик берләшмәсенә тәкъдимнәр җибәрелде. Федераль министрлык белән эш дәвам итә.

*Канун нигезендә белем бирү программасы мәктәп тарафыннан мөстәкыйль эшләнә, кабул ителә һәм гамәлгә ашырыла, шул исәптән предметларны өйрәнүгә бирелә торган сәгатьләр саны да.*

***

Республикабызның күпмилләтле, татар теленең дәүләт теле булуын исәпкә алып республика мәктәпләрендә туган телләрне өйрәнүне тәэмин итү – безнең бурыч.

Шул ук вакытта, республикада туган телдә белем алу, туган телләрне өйрәнү өчен **барлык уку йортларында да шартлар тудырылган** булуын ассызыклыйм һәм киңрәк тукталам.




Министрлык тарафыннан милли мәгариф мәсьәләләре белән шөгыльләнүче структура булдырылды. Ул үз эченә Министрлыкның милли мәгариф идарәсен, Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасын, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге, муниципаль берәмлекләренең мәгариф органнарының милли мәгариф өчен җаваплы методистларынала. Казан федераль университеты белән тыгыз хезмәттәшлек оештырылды. Министрлык тарафыннан Мәгариф идарәләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары катнашында уку йортларында туган телдә белем бирү, туган телләрне укыту буенча эшлекле киңәшмәләр, методистлар һәм укытучылар өчен ай саен семинарлар, курслар уздырыла.

****

Белем бирүнең беренчел һәм тел өйрәнүдә иң үтемле баскычы – мәктәпкәчә белем бирү.



ТУГАН ТЕЛДӘ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ

**2 008 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы**
Шул исәптән:

745 татар телендә белем һәм тәрбия бирүче
1 195 рус телендә белем һәм тәрбия бирүче, шул исәптән:
644 бакчада – 1 294 татар төркеме булган оешмалар
46 чуваш телендә белем һәм тәрбия бирүче
13 удмурт телендә белем һәм тәрбия бирүче
9 мари телендә укыту һәм тәрбия бирүче

Республикада мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирүнең тулы системасы булдырылды, туган телдә белем һәм тәрбия бирүче балалар бакчалары челтәре саклана.



БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫНЫҢ УКЫТУ-МЕТОДИК БАЗАСЫН НЫГЫТУ

| Алынган продукт | Күләме | Барлыгы, млн.сум |
|---|---|---|
| Өстәл уеннары, матур әдәбият китаплары | 17 уен төрле күләмдә | 6,1 |
| Район үзәгенә урнашкан татар телендә тәрбия бирүче бакчаларга интерактив җиһаз | 21 бакча | 6,7 |
| Муниципаль районнарның әйдәп баручы балалар бакчасына уеннар, милли киемнәр, курчак театры, интерактив җиһаз, ноутбук (ПАО «Татнефть») | 45 комплект | 9,0 |
| «Туган телдә сөйләшәбез» - УМК | 7 УМК х 2000 данә | 9,26 |
| Күренекле шәхесләрнең портретлары, цитаталары белән плакатлар (фонд) | 10 портрет х 950 данә | 4,01 |
| Татар теле кабинетлары өчен татар әдипләренең портретлары (фонд) | 5 портрет х 800 данә | 2,69 |
| Музыкаль китаплар (ПАО «Татнефть») | 3 китап х 11 000 данә | 13,6 |
| Балалар өчен энциклопедияләр (фонд) | 6 китап х 3000 данә | 2,7 |

Барлык балалар бакчаларында да балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү программалары тормышка ашырыла.Тел мохитен киңәйтү һәм инновацион технологияләр кертү максатыннан Комиссия ярдәме белән Татар китап нщшрияте тарафыннан укыту-методик комплектлар, матур әдәбият, өстәл уеннары эшләнде һәм балалар бакчаларына кайтарылды. Бакчаларның туган тел кабинетлары өчен интерактив җиһазлар сатып алынды.

Һәр муниципаль берәмлектә балалар бакчаларында туган телдә белем һәм тәрбия бирү өчен шартлар тудыру максаты куелды.

**2021/2022 УКУ ЕЛЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕНЕҢ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ БИРҮ КҮРСӘТКЕЧЕ (%)**

**Татарстан Республикасы буенча 56,3**

| Мун. берәмлек | Туган татар телендә белем һәм тәрбия бирү | | | Мун. берәмлек | Туган татар телендә белем һәм тәрбия бирү | | | Мун. берәмлек | Туган татар телендә белем һәм тәрбия бирү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 01.01. 2020 | 01.01. 2021 | 01.01. 2022 | | 01.01. 2020 | 01.01. 2021 | 01.01. 2022 | | 01.01. 2020 | 01.01. 2021 | 01.01. 2022 |
| Әгерҗе | 29,50 | 35,50 | 43,09 | Биектау | 61,60 | 58,00 | 62,16 | Яңа Чишмә | 66,10 | 72,00 | 72,22 |
| Азнакай | 44,00 | 47,40 | 69,86 | Чүпрәле | 44,40 | 45,40 | 45,37 | Норлат | 49,70 | 53,40 | 53,57 |
| Аксубай | 36,80 | 32,20 | 34,10 | Алабуга | 34,00 | 33,00 | 38,98 | Питрәч | 45,70 | 57,40 | 60,61 |
| Актаныш | 100,00 | 100,00 | 100,00 | Зәй | 39,60 | 36,50 | 37,68 | Б.Бистәсе | 46,30 | 49,60 | 52,14 |
| Алексеевск | 40,30 | 31,50 | 50,49 | Яшел Үзән | 23,10 | 28,60 | 34,56 | Саба | 93,30 | 93,80 | 94,45 |
| Әлки | 58,30 | 58,90 | 62,17 | Кайбыч | 95,30 | 92,90 | 93,08 | Сарман | 60,40 | 63,80 | 63,84 |
| Әлмәт | 61,70 | 61,00 | 64,31 | Кама Тамагы | 39,20 | 41,70 | 42,67 | Спасс | 22,60 | 48,30 | 55,00 |
| Апас | 92,40 | 100,00 | 95,06 | Кукмара | 57,90 | 57,10 | 59,33 | Тәтеш | 41,50 | 42,70 | 42,77 |
| Арча | 67,40 | 65,40 | 68,33 | Лаеш | 57,20 | 53,60 | 56,41 | Тукай | 62,40 | 37,10 | 52,81 |
| Әтнә | 100,00 | 100,00 | 100,00 | Лениногорск | 38,60 | 40,80 | 43,12 | Теләче | 81,30 | 81,70 | 81,72 |
| Баулы | 63,50 | 53,20 | 51,90 | Мамадыш | 50,80 | 51,40 | 53,25 | Чирмешән | 61,70 | 68,60 | 58,03 |
| Балтач | 97,10 | 97,30 | 97,39 | Менделеевск | 34,40 | 21,00 | 22,68 | Чистай | 25,30 | 27,00 | 36,79 |
| Бөгелмә | 82,90 | 86,40 | 86,37 | Минзәлә | 37,70 | 36,20 | 36,73 | Ютазы | 40,30 | 37,30 | 38,97 |
| Буа | 28,10 | 36,20 | 38,89 | Мөслим | 99,40 | 100,00 | 97,65 | Яр Чаллы | 57,80 | 53,80 | 53,97 |
| Югары Ослан | 0,00 | 0,00 | 0,00 | Түбән Кама | 47,80 | 47,60 | 57,75 | Казан | 45,60 | 49,00 | 50,62 |

9

Агымдагы елда барлык районнарда диярлек бу юнәлештә сизелерлек эш күренә.

*Кызганычка каршы, Менделеевск районында күрсәткеч бик түбән, Югары Ослан районында бу өлкәдә эш оештырылмаган.*

Шул ук вакытта, мәгариф оешмаларынан сыйфат өстендә эшне активлаштыру сорала. Бу юнәлештә район һәи шәһәр башлыкларының, мәгариф идәрәләре, балалар бакчалары җитәкчеләренең намуслы, җаваплы эшләве мөһим.

***

Тел мохитен саклауда мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирүнең дәвамчанлыгын тәэмин итү, ата-аналар белән аңлату эшләрен дөрес оештыру зарур.

**ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА УКУЧЫЛАРНЫҢ МИЛЛИ СОСТАВЫ**



| | |
|---|---|
| 222 719 | татар |
| 172 997 | рус |
| 8 193 | чуваш |
| 2 189 | удмурт |
| 1 352 | мари |
| 732 | башкорт |
| 566 | мордва |
| 2 903 | таҗик |
| 2 230 | үзбәк |
| 1 905 | әзербайҗан |
| 1 055 | әрмән |
| 35 174 | катнаш гаиләләр |

11

Республикабыз уку йортларында белем алучы балаларның милли составын экранда күрәсез.



2021/2022 УКУ ЕЛЫНДА МИЛЛИ-МӘДӘНИ КОМПОНЕНТЛЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ

| Милләт | Гомуми мәктәп саны | Шул исәптән юридик зат | Шул исәптән филиал | Бала саны |
|---|---|---|---|---|
| татар | 629 | 511 | 118 | 79 673 |
| чуваш | 89 | 67 | 22 | 4 072 |
| удмурт | 22 | 17 | 5 | 1 543 |
| мари | 16 | 15 | 1 | 939 |
| мордва | 3 | 2 | 1 | 39 |

11

2021/2022 уку елында республикада туган телдә белем һәм тәрбия бирүче 760мәктәп, шул исәптән 147 филиал эшли.



«ТУГАН ТЕЛ» ПРЕДМЕТЫН УКЫТУ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

| Туган тел | 2019/2020 | | 2020/2021 | | 2021/2022 | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бала саны | % | бала саны | % | бала саны | % |
| татар | 282 503 | 67,23 | 286 298 | 65,26 | **289 175** | **63,34** |
| рус | 131 372 | 31,19 | 144 438 | 33 | **161 288** | **35,33** |
| чуваш | 4 378 | 1,05 | 4 102 | 1,0 | **3 860** | **0,85** |
| удмурт | 1 060 | 0,25 | 1 030 | 0,23 | **1 040** | **0,23** |
| мари | 498 | 0,12 | 455 | 0,10 | **465** | **0,1** |
| мордва | 49 | | 42 | 0,01 | **39** | **0,01** |
| башкорт | | | 0 | | **8** | |
| иврит | 644 | 0,15 | 672 | 0,15 | **694** | **0,15** |

12

7 тел туган тел буларак өйрәнелә (рус, татар, чуваш, удмурт, мари, мордва, башкорт, иврит).



Республиканың 19 районында чуаш этномәдәни компонентлы мәктәпләр эшләп килә һәм чуаш телен өйрәнү оештырылган.




6 районда - удмурт




9 районда - мари




3 районда мордва этномәдәни компонентлы мәктәп эшли.

ЯКШӘМБЕ МӘКТӘПЛӘРЕ

**100 түгәрәк** **25 милләт**

**1 749 бала саны**

чуваш, удмурт, мари, мордва, әзербәйҗан, украин, әрмән, таҗик, үзбәк, әфган, немец, грузин, лезгин, бурят, вьетнам, кыргыз, башкорт һәм башка халыкларның теле, мәдәнияте, тарихы өйрәнелә

17

Моннан тыш, якшәмбе мәктәбенең 100 бүлегендә 25 милләт теле һәм мәдәнияте өйрәнелә. Якшәмбе мәктәпләре Татарстан халыклары Ассамблеясе һәм аның бүлекчәләре белән тыгыз элемтәдә эшли.

***

**2021/2022 УКУ ЕЛЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕНЕҢ МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ АЛУ КҮРСӘТКЕЧЕ (%)**

| Мун. берәмлек | Татар телендә БЕЛЕМ бирү | Татар телендә белем һәм тәрбия бирү | Мун. берәмлек | Татар телендә БЕЛЕМ бирү | Татар телендә белем һәм тәрбия бирү | Мун. берәмлек | Татар телендә БЕЛЕМ бирү | Татар телендә белем һәм тәрбия бирү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Әгерҗе | 25,0 | 33,91 | Биектау | 34,07 | 46,85 | Яңа Чишмә | 52,69 | 63,84 |
| Азнакай | 32,5 | 100,00 | Чүпрәле | 60,52 | 81,88 | Норлат | 13,99 | 53,13 |
| Аксубай | 41,6 | 43,80 | Алабуга | 40,48 | 53,89 | Питрәч | 15,24 | 36,22 |
| Актаныш | 97,3 | 97,32 | Зәй | 17,35 | 37,15 | Балык Бистәсе | 39,11 | 51,76 |
| Алексеевск | 28,2 | 32,9 | Яшел Үзән | 30,83 | 40,01 | Саба | 34,38 | 100,00 |
| Әлки | 45,47 | 63,68 | Кайбыч | 58,60 | 73,99 | Сарман | 48,58 | 58,47 |
| Әлмәт | 17,82 | 29,99 | Кама Тамагы | 44,19 | 48,66 | Спасс | 24,44 | 31,19 |
| Апас | 58,74 | 71,80 | Кукмара | 46,25 | 53,27 | Тәтеш | 33,40 | 37,85 |
| Арча | 54,73 | 90,42 | Лаеш | 30,93 | 45,85 | Тукай | 48,79 | 56,47 |
| Әтнә | 65,07 | 100,00 | Лениногорск | 18,85 | 21,34 | Теләче | 49,00 | 92,40 |
| Баулы | 23,08 | 28,93 | Мамадыш | 25,15 | 51,87 | Чирмешән | 37,10 | 64,68 |
| Балтач | 53,64 | 75,02 | Менделеевск | 13,28 | 13,28 | Чистай | 17,37 | 25,74 |
| Бөгелмә | 25,16 | 47,57 | Минзәлә | 40,19 | 40,19 | Ютазы | 44,16 | 47,01 |
| Буа | 33,17 | 41,99 | Мөслим | 32,05 | 97,70 | Яр Чаллы | 7,76 | 30,46 |
| Югары Ослан | 0,00 | 0,00 | Түбән Кама | 14,82 | 22,28 | Казан | 19,29 | 55,59 |
| Татарстан Республикасы буенча | | | | 24,78 | 50,13 | | | |

18

Татар телендә белем һәм тәрбия бирүгә килгәндә, республика буенча туган телдә белем алу курсәткече – 24,8%, тәрбия бирү – 25, 4%.

Комиссия тәкъдиме белән Министрлар Кабинеты карары нигезендә әлеге күрсәткеч муниципаль районнар эшчәнлегенең нәтиҗәлек күрсәткечләре исемлегенә кертелде.

2021елда барлык районнарда милли мәгарифкә булган игътибар сизелерлек артты. Комиссия, Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын оештыру комитеты әгъзалары тарафыннан милли мәгариф сораулары буенча семинарлар,

эшлекле очрашулар уздырылды. Туган телләрне куллану даирәсен киңәйтүгә юнәлтелгән чаралар үтте.

*Аерым районнарга килгәндә:*

*Милли мәгарифкә зур игътибар бирүчеләрдән Актаныш, Апас, Арча, Әтнә, Балтач, Чүпрәле, Кайбыч районнарын атар идем,*

*ә менә Әлмәт, Баулы, Зәй, Лениногорск, Менделеевск, Яр Чаллы, Түбән Кама, Норлат, Питрәч, Чистай районнарына игътибарны арттыру сорала. Кызганыч, Югары Ослан районында туган телдә белем һәм тәрбия бирү гомумән оештырылмаган.*




Балада туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту өчен белем бирү процессы кызыклы,мавыктыргыч булырга, уңай эмоцияләр уятырга тиеш.




Коммуникатив технологияләр кулланып практик юнәлешле программалар эшләү һәм гамәлгә кертү – беренче юнәлеш.

Татар теленнән республикабызның дәүләт теле һәм туган тел буларак,татар әдәбиятыннан эшләнгән программалар федераль реестрга кертелде.




Республикада укучыларның тел белү дәрәҗәсен исәпкә алып, 3 юнәлеш буенча татар теле һәм әдәбияты буенча программалар һәм дәреслекләр эшләнде:

*туган телендә белем бирүче мәктәп укучылары өчен;*

*рус телендә белем бирүче мәктәпләрдә татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен;*

*рус телендә белем бирүче мәктәпләрдә татар телен Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак өйрәнүче укучылар өчен.*

Бүгенге көндә татар теле һәм әдәбиятыннан 89 дәреслек федераль исемлеккә кертелгән. Моннан тыш мәктәпләрдә 31 уку әсбабы кулланыла.




Туган телләрне укыту методикасын заман таләпләренә туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге, Мәгарифне үстерү институты белән яңа буын дәреслекләрэшләнде. Төп мәктәп өчен басмалар әзерләү тәгәлләнә.




Татар китап нәшрияты белән берлектә татар теленә тәрҗемә ителгән дәреслекләрне федераль исемлеккә кертү эше оештырылды, 38 комплект Россия Федерациясе мәгариф министрлыгына тапшырылды.

Авторлык хокуклары буенча норматив билгеләнү булмау сәбәпле, тәрҗемә басмаларын исемлеккә кертү федераль министрлык ягыннан сораулар тудырды, Бу уңайдан Мәгариф министрлыгы җитәкчелеге белән очрашулар булды, Татарстан Республикасы Президенты имзасы белән мөрәҗәгать юлланды.

Гаризалар кабул ителде, экспертиза оештырылды.Дәреслекләр буенча фәнни-методик совет утырышы карары белән әсбаплар өстәмә экспертизага җибәрелде һәм шул ук совет карары белән татар теленнән 12 әсбап, шул исәптән алда әйтелгән яңа буын дәреслекләр һәм 1-4 сыйныфлар өчен математикадан тәрҗемәи дәреслек федераль исемлеккә кертү өчен лаеклы дип табылды.

Татарстан китап нщшрияте тарафыннан агымдагы елда федераль исемлеккә кертү өчен, 5-9 сыйныфларда төп фәннәр буенча 41 әсбап әзерләнә.




Бюджет исәбеннән чуаш, удмурт, мари, мордва телләре буенча дәреслекләр, уку ярдәмлекләре сатып алына.

Бүген федераль исемлеккә удмурт теле дәреслекләре кертелгән. Чуаш теле буенча агымдагы елда керер дип көтәбез.

***

Цифрлаштыру шартларында укучыларның кызыксынуын арттыру механизмнарының берсе – белем бирү процессына мәгълүмати технологияләр кертү.




2013 елдан башлап республика бюджеты исәбенә барлык теләүчеләр өчен бушлай «Ана теле» онлайн мәктәбе эшли. Бүгенге көндә мәктәпне кулланучылар саны 35 меңнән артык кеше тәшкил итә.




2021 елда Фәннәр академиясе, Мәгарифне үстерү институты белән берлектә «Туган тел», «Туган телдә әдәбият», «Татарстан Республикасы дәүләт теле - татар теле» фәннәре буенча Сберкласс платформасында татарча контент эшләнде. Бүгенге көндә барлык мәктәпләр дә әлеге платформага теркәлү үтте һәм ресурстан файдалана башлады.




Республиканың дәүләт программалары кысаларында татар телендә интерактив проектлар, мобиль кушымталар һәм компьютер программалары булдыру эше дәвам итә.




Татар теле укытучыларына ярдәмлек буларак КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты белән берлектә һәр сыйныф өчен биш юнәлештә татар теле һәм әдәбияты буенча тестлар системасы эшләнде һәм министрлык сайтына урнаштырылды. *Система үз эченә һәр дәрестә куллану өчен, контроль эшләр, арадаш аттестация өчен биремнәр базасын, аудиоматериалларны, биремнәргә аңлатмалар, үрнәк биремнәр банкын ала.*




Канун нигезендәчыгарылыш сыйныф укучыларына туган тел һәм әдәбият фәннәреннән имтихан тапшыру мөмкинлеге бирелә.

Татар телендә белем алган укучылар өчен 9 сыйныфтан соң сигез фәннән(математика, химия, биология, география, физика, тарих, җәмгыять белеме, информатика)имтиханнытатар телендә тапшыру өчен шартлар тудырылган.

9 нчы сыйныфтан соң ел саен туган телне мең ярым (1500) укучы сайлый, 11 сыйныфтан соң теләүчеләр бик аз, агымдагы елда 2 укучы (Балтач, Теләче районнары).

Бала бердәм дәүләт имтиханын югары уку йортына керү өчен сайлый. Әмма «Туган тел»буенча имтихан нәтиҗәләре бер генә уку йортында да керү сынавы булара кабул ителми. Россиядә барлыгы 74 тел укытыла,25 төбәкнең 34 уку йортында 43 телдән укытучылар әзерләнә. Сынаулар исемлеге Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы приказы белән расланган һәм без приказда журналистика, культурология, театр сәнгате, филология юнәлеше буенча сынаулар исемлегенә «туган тел» фәнен кертүне сорап мөрәҗәгать иттек. Кызганыч, җавапта, уку йортлары өстәмә эчке имтихан буларак «туган тел» фәннәреннән сынау куя ала дип күрсәтелде. Әмма, бу чишелеш түгел. Бу өстәмә сынау һәм ул кызыксындыру чарасы була алмый.

Республиканың ректорлар советы, КФУ белән бу турыда киңәшмәләр уздырылды, исемлектә «туган тел» фәне булган очракта, һичшиксез, аның сынау буларак куелачагы ассызыкланды.Әйткәнемчә, агымдагы елда 11 нче сыйныфтан соң бары тик ике бала татар теленнән сынау бирергә теләк белдерде. Теләк уйланылган, балалар татар филологиясе бүлегенә укырга бара. Бу елда КФУ кабул итү комиссиясе карары белән татар теленнән бердәм республика имтиханын эчке сынауитеп таныячагын белдерде. Алга таба да бу юнәлештә эшләячәкбез.

**ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ УКЫТУ-МЕТОДИК БАЗАСЫН НЫГЫТУ**

| Алынган продукт | Күләме | Барлыгы, млн.сум |
|---|---|---|
| Татар теле дәреслекләре һәм укыту әсбаплары белән тәэмин итү | 15 УМК | 16,3 |
| Татар телендә белем бирүче мәктәпләр өчен интерактив җиһазлар | 135 данә | 23,0 |
| Татар телендә белем бирүче мәктәпкә интерактив җиһаз (ПАО «Татнефть») | 20 данә | 5,0 |
| Туган тел һәм әдәбияты кабинеты өчен интерактив җиһазлар | 203 данә | 46,0 |
| Мәктәп китапханәләренә «Татар балалар нәшрияты» басмаларын кайтару (фонд) | 6 китап х 1 400 данә | 3,99 |
| Татар теле кабинетлары өчен татар әдипләренең портретлары (фонд) | 15 портрет х 1 402 данә | 21,02 |
| Туган тел кабинетлары өчен плакатлар | 10 плакат х 700 данә | 7,0 |

30

Туган телдә белем бирүче мәктәпләрнең дәрәҗәсен, туган телне укытуның сыйфатын күтәрүне стимуллаштыру да актуаль булып тора.

Белем бирү процессына мәгълүмати технологияләр кертү максатында 2021 елда мәктәпләргә 300 дән артык интерактив җиһазкайтарылды. Мәктәпләрнең укыту-методик базасы ныгытылды, татар теле кабинетлары язучыларыбызның портретлары белән баетылды. Комиссиягә, һәм шәхсән Марат Готовичка зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Алга таба да уртак эшчәнлеккә ышанабыз һәм сынатмаска ышандырабыз.

***



МИЛЛИ МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ БИРЕЛГӘН ГРАНТЛАР

| Грант исеме | Грант саны | 1 оешмага, мең сум | Барлыгы, млн.сум |
|---|---|---|---|
| Балаларны туган (татар, чуваш, удмурт, мари, мордва) телдә укытуны һәм тәрбияләүне оештыру буенча иң яхшы балалар бакчасы | 20 | 500,0 | 10,0 |
| Татарстан Республикасының муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында туган телдә (татар, чуаш, удмурт, мари, мордва) укытуның иң яхшы тәҗрибәсе | 20 | 500,0 | 10,0 |
| Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыруда муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына ярдәм | 100<br>100 | 500,0<br>500,0 | 100,0 |
| Иң яхшы билингваль балалар бакчасы | 10 | 500,0 | 5,0 |

31

2020 елда Комиссия тәкъдиме белән туган телдә белем бирү оешмалары өчен республика конкурслары үткәрелеп 40 уку йорты 500 мең күләмендә грантка ия булса,

2021 елда республика территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен саклауга юнәлтелгән проектларны тормышка ашыругагрантка 200 уку йорты лаек булды.




Агымдагы елда шундый ук бәйге игълан ителде. Ул ике этапта узачак, нәтиҗәләр май аенда ясалачак. Шулай ук 200 җиңүче 500 мең күләмендә премия белән бүләкләнәчәк.

****




Алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырган укытучы да бар һәм туфрак булачак бер баланы алтын итә белгән укытучы да бар – дип язган мәгърифәтчебез  Ризаэтдин Фәхретдин. Дәресне яратып, тел өйрәнүдә баланың нәтиҗәгә ирешүе – эти-әни өчен күрсәткеч. Монда беренче урынга укытучының осталыгы, оештыру сәләте чыга.




| Укытучылар | БАРЛЫГЫ | Белеме | | Эш стажы | | | категориясе | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | югары | Урта һөнәри | 0-3 ел | 3-10 ел | 10 елдан артык | югары | беренче | СЗД | катег. юк |
| Татар теле | 3 402 | 3 370 | 28 | 61 | 303 | 3 038 | 888 | 2 107 | 226 | 181 |
| Чуаш теле | 87 | 86 | 1 | 2 | 3 | 82 | 14 | 63 | 1 | 9 |
| Мари теле | 15 | 14 | 1 | 0 | 0 | 15 | 4 | 9 | 0 | 2 |
| Удмурт теле | 19 | 18 | 0 | 1 | 0 | 18 | 9 | 8 | 0 | 2 |
| Мордва телләре | 2 | 2 | 0 | 0 | 0 | 2 | 0 | 2 | 0 | 0 |

Бүген республика мәктәпләрендә3мең ярымнан артык (3526) туган тел укытучысы эшли. Туган телдә белем бирүче мәктәпләрдә эшләүче укытучылар саны 12 меңнән артык. *Нәкъ менә алар туган тел һәм әдәбият аша, дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша яшь буында туган илгә, тарихи мираска мәхәббәт тәрбияли.*




Укытучыларны әзерләүнең, аларның белемнәрен күтәрүнең тотрыклы системасын булдыру шулай ук зур урын ала.

Туган телдә белем бирүче укытучыларны әзерләү максатыннан Президентыбыз йөкләмәсе буенча КФУ структурасында Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе төзелде. Республика хисабына бүген анда 532студентбелем ала.Агымдагы елда фәннәрне 3 телдә укытуга әзерлек төркемнәретупланды.

Министрлык тарафыннан максатчан рәвештә районнар һәм Казан федераль университеты белән берлектә эш оештырылды.




| оешманың исеме | 2016/2017 | | 2017/2018 | | 2018/2019 | | 2019/2020 | | 2020/2021 | | 2021/2022 | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кабул итү | чыгарылыш | кабул итү | чыгарылыш | кабул итү | чыгарылыш | кабул итү | чыгарылыш | кабул итү | чыгарылыш | кабул итү | чыгарылыш |
| Арча педагогика көллияте | 50 | 23 | 58 | 57 | 57 | 55 | 59 | 50 | 54 | 52 | 50 | 49 |
| Минзәлә педагогика көллияте | 45 | | 20 | 15 | 25 | 20 | 25 | 25 | | 16 | 50 | 19 |
| Казан педагогика көллияте | | | 33 | | | | | | | 33 | 50 | |
| Яр Чаллы педагогика көллияте | | | | | | | | | | | 50 | |
| Түбән Кама педагогика көллияте | | | | | | | | | | | 25 | |
| Барлыгы | 95 | 23 | 91 | 72 | 82 | 75 | 84 | 75 | 54 | 101 | 225 | 68 |

Моннан тыш, педагогик кадрлар әзерләү алты һөнәри белем бирү оешмасында гамәлгә ашырыла. Агымдагы елда милли мәгариф юнәлешенә 5 уку йортына 225 студент кабул ителде.

*****




| Грант исеме | Грант саны | 1 укытучыга, мең сум | Барлыгы, млн.сум |
|---|---|---|---|
| Татар телендә белем бирүче педагогик хезмәткәрләр өчен грант | 2020ел 100 | 50,0 | 5,0 |
| Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыруга туган телдә укытучы педагог хезмәткәрләр арасында республика конкурсы | 2022ел 100 | 50,0 | 7,5 |
| Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыруга туган телдә белем һәм тәрбия бирүче тәрбиячеләр арасында республика конкурсы | 2022ел 100 | 50,0 | 7,5 |
| Туган (татар) теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадаларында һәм татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне әзерләгән өчен туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучыларына грант | Ел саен 13 | 100,00 | 1,5 |

Туган телдә белем һәм тәрбия бирүче укытучылар өчен Комиссия инициативасы һәм ярдәме белән 100 укытучыга төрле проектларны гамәлгә ашыру өчен 50 мең күләмендә грант бирелде. Бу проектларның нәтиҗәләре Министрлык сайтына урнаштырылды. Быелэлеге конкурс май-июнь айларында узачак.

Моннан тыш, ел саен, балаларны татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларга нәтиҗәле әзерләгән өчен аерым грант бәйгесе уздырыла.




Иң яхшы педагогик тәҗрибәләрне ачыклау максатыннан ел саен «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» бөтенроссия бәйгесе уза. Бу көннәрдә Казан шәһәренең полилингваль комплексы базасында 32 укытучы көч сынаша, шул исәптән 12 укытучы Россия регионнарыннан. Нәтиҗәләр 25 мартта ясалачак.

28-29 март көннәрендә башкалабызда туган тел укытучыларының «Туган тел» мастер класс бәйгесе узачак. Барлыгы республикадан 72, Россия регионнарыннан 22 гариза кабул ителде. 50 укытучы сайлап алу турын узды. Нәтиҗәләр 29 мартта ясалачак.

******







Республика халыклары телләрен саклауга һәм үстерүгә татар һәм рус телләре буенча үткәрелә торган халыкара олимпиадалар, «Илһам» язучылар конкурсы, мәктәп театрлары фестивале, якшәмбе мәктәпләре слеты, фәнни-гамәли конференцияләр һәм олимпиадалар, төбәкара профильле тел лагерьлары, *барлыгы 150 дән артык чара* йогынты ясый.

****



Тел сәясәтен гамәлгә ашыруда Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, милли-мәдәни автономияләр һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек зур әһәмияткә ия.

Хәзерге вакытта Россиянең 26 субъектында уку планнары кысаларында татар теле өйрәнелә, җиде төбәктә татар телен, мәдәниятен, тарихын өйрәнү буенча ял көне мәктәпләре эшли.




Төбәкләрдә татар мәгърифәте көннәре, төбәкара семинарлар уздырыла. Мәгарифне үстерү институты базасында ел саен милли мәктәп укытучылары өчен квалификация күтәрү курслары, ай саен – вебинарлар үткәрелә.2021 елда гына да татар телендә белем бирүче мәктәпләргә 6,5 млн. сумлык 14 меңнән артык дәреслек түләүсез тапшырылды. Агымдагы елда планда татар теле укытучыларының Бөтенроссия съездын үткәрү.

*Хөрмәтле утырышта катнашучылар, туган телләрне өйрәнү өчен шартлар тудыру, туган телне өйрәнү, туган телне һәм әдәбиятны укытуның нәтиҗәлеген арттыру, укыту методикасын камилләштерү - бу уртак тырышлык белән хәл итәргә мөмкин булган бурычлар. Бүгенге киңәшмә безгә әлеге мәсьәләне тагын бер кат актуальләштерергә ярдәм итәр дип ышанам.*




Чыгышымны Президентыбыз Рөстәм Нургали улы сүзләре белән тәмамлыйсым килә:

«Без үз киләчәгебезне халкыбызның мәдәни мирасын саклауда һәм баетуда күрәбез… Без киләчәктә дә үз тарихыбызны үзебез язарга, үз киләчәгебезне үзебез төзергә телибез! Киләчәгебез якты һәм бик күп, бик күп буыннар өчен уңышлы булсын иде!




Игътибарыгыз өчен рәхмәт!